30

# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасының Югары
арбитраж суды турында

I маддә. Төп тешенчәләр

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды - предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр арасында гражданлык хокук мөнәсәбәтләреннән яки идарә өлкәсендәге хокук мөнәсәбәтләреннән барлыкка килә торган икътисади бәхәсләрне хәл итә торган югары суд хакимияте ул.

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды юридик затлар /алга таба - предприятиеләр/ рәвешендәге предприятиеләр, учреждениеләр,оешмалар /колхозларны да кертеп/ арасындагы,шулай ук юридик зат булмыйча гына, эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнгән һәм закон билгеләгән тәртиптә эшкуарлык статусына ия булган гражданнар /алга таба - эшкуар гражданнар/ арасындагы бәхәсләрне хәл итә.

Закон актларында билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды бәхәсләрне дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары катнашында, шулай ук юридик зат булмаган оешмалар катнашында хәл итә.

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының Арбитраж гамәли мәҗмугасында каралган очракларда бәхәсләрне чит ил инвестицияләре кертелгән

оешмалар, башка дәүләт территориясендә урнашкан предприятиеләр һәм эшкуар гражданнар катнашында хәл итә.

2 маддә. Татарстан Республикасының Югары арбитраж судын оештыру, аның эшчәнлегенең тәртибе һәм вәкаләтләре турында законнар

Татарстан Республикасының Югары арбитраж судын оештыру, аның эшчәнлегенең тәртибе һәм вәкаләтләре әлеге Закон, Татарстан Республикасының Арбитраж гамәли мәҗмугасы һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка закон актлары тарафыннан билгеләнә.

3 маддә. Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының бурычлары

Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

предприятиеләрнең, эшкуар гражданнарның закон тарафыннан саклана торган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау;

законнарның үтәлешенә һәм икътисади мөнәсәбәтләрдә законлылыкны ныгытуга хокукый гамәлләр аша ярдәм итү;

законнарны бер төрле һәм дөрес куллану.

4 маддә. Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды эшчәнлегенең төп үзенчәлекләре

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды эшчәнлегенең төп үзенчәлекләре бәхәсләрне бергәләп хәл итүеннән, Югары арбитраж судының һәм судьяларының бәйсезлегеннән һәм аларның бары тик законнарга гына буйсынуыннан, якларның тигез хокуклылыгыннан, бәхәсләрне  хәл итүнең хәбәрдарлыгыннан, карарларның законлылыгыннан һәм нигезлегеннән гыйбарәт.

5 маддә. Икътисади бәхәсләрнең Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды карамагында булуы

Предприятиеләр, эшкуар гражданнар, нинди ведомство карамагында булуларына, якларның кемгә буйсынуларына һәм түбәндәге сәбәпләр аркасында килеп чыккан таләпләргә карамастан, Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды карамагында булалар:

аңлашманамәләрне төзүгә бәйле очракларда, әгәр якларның килеп чыккан яки килеп чыгу мөмкинчелеге булган бәхәсләрне Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды карамагына тапшыру турында килешүләре булса яисә әлеге тапшыру закон актларында каралган булса;

шартларны үзгәртү яисә аңлашманамәләрне өзү;

йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешле рәвештә үтәмәү;

милекчелек хокукын тану;

чит кешенең законсыз биләвендә булган мөлкәтне милекченең яисә законлы биләүченең таләп итүе;

биләүдән мәхрүм итү белән бәйле булмаган рәвештә милекченең яисә законлы биләүченең хокукларын бозу;

башка предприятиегә, эшкуар гражданга зыян китерү;

предприятиеләрнең, эшкуар гражданнарның намусын һәм абруен яклау, товар тамгасын, эмблеманы, хезмәт күрсәтү тамгасын һәм предприятиеләр исемен куллану;

предприятиенең, эшкуар гражданның хокукларын бозганга кадәр булган халәтләрен торгызуның, предприятиеләрнең һәм эшкуар гражданнарның хокукларын бозучы гамәлләргә чик куюның зарурияте;

башка сәбәпләр.

Предприятиеләрнең, эшкуар гражданнарның берәрсе чит дәүләт территориясендә урнашкан очракта, алар арасындагы бәхәсләр, Татарстан Республикасының дәүләтара килешүләрендә, халыкара аңлашманамәләрендә яисә якларның килешүләрендә каралган булса,

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды карамагында була.

Предприятиеләрнең чит ил инвестицияләре кертелгән предприятиеләр белән булган бәхәсләре, әгәр бу дәүләтара килешүләрдә яисә якларның килешүләрендә каралган булса, Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды карамагында була.

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды, сәбәпләр булса, үз инициативасы нигезендә арбитраж эшен кузгата ала, шулай ук предприятиенең банкротлыгын тану турында мәсьәләне карый ала.

6 маддә. Идарә өлкәсендәге бәхәсләрнең Татарстан Республикасы арбитраж суды карамагында булуы

Идарә өлкәсендәге түбәндәге бәхәсләр Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды карамагында була:

дәүләт органнарының һәм башка органнарның /аерым затларга яисә затлар төркеменә адресланган/ законнарга туры килмәүче һәм предприятиеләрнең, эшкуар гражданнарның закон тарафыннан саклана торган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозучы актларын, шул исәптән халык депутатлары Советларының һәм администрациясенең карарларын дөрес түгел /тулысынча яисә өлешчә/ дип тану турында;

предприятиеләргә һәм эшкуар гражданнарга әлеге актлар аркасында килгән зыянны каплау турында, шулай ук югарыда күрсәтелгән органнарның предприятиеләргә һәм эшкуар гражданнарга карата үз вазыйфаларын тиешенчә үтәмәү аркасында килгән зыянны каплау турында;

җир биләмәләрен бирүдән баш тарту хакында яисә аларны тартып алу турында халык депутатлары Советларының карарлары белән риза булмыйча, шикаять бирү турында;

предприятиеләрнең яисә гражданнарның эшкуарлык эшчәнлеген дәүләт тарафыннан теркәүдән баш тарту яисә билгеләнгән вакытта дәүләт тарафыннан теркәмәскә тырышу белән риза булмыйча, шикаять бирү турында;

дәүләт органнарының һәм башка органнарның предприятиеләрдән һәм эшкуар гражданнардан акчаларын һәм башка мөлкәтләрен тартып алу турындагы карарлары, шулай ук законсыз тартып алынган

акчаларны һәм башка милкәтләрне кайтару турындагы карарлары белән риза булмыйча, шикаять бирү хакында;

дәүләт органнары һәм башка органнар тарафыннан, шул исәптән монополиягә каршы сәясәт алып баручы органнар, банклар, инспекцияләр, башка тикшерүче органнар тарафыннан предприятиеләрдән һәм эшкуар гражданнардан штрафлар һәм башкача акча алу турында, әгәр законнарда бәхәссез рәвештә шушы акчаларны исәптән чыгару каралмаган булса.

икътисади /финанс/ санкцияләре рәвешендә һәм бүтән сәбәпләр аркасында дәүләт салым инспекцияләре һәм башка тикшерүче органнар тарафыннан, закон таләпләрен бозып, бәхәссез рәвештә исәптән чыгарылган акчаларны бюджеттан кире кайтару турында.

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды карамагында тагын түбәндәгеләр була:

дәүләт ихтыяҗлары өчен продукция, товарлар бирү, эшләр башкару /хезмәт күрсәтү/ турында аңлашманамәләр /контрактлар/ төзү буенча бәхәсләр;

дәүләт ихтыяҗлары өчен продукция, товарлар бирүгә, эшләр башкаруга /хезмәт күрсәтүгә/ заказлар кабул итү турында аңлашманамәләрнең /контрактларның/ шартлары буенча әлеге заказларны бирүче дәүләт органнары һәм башка органнар /оешмалар/ белән заказларны үтәү буенча үзләренә йөкләмә алган предприятиеләр яки эшкуар гражданнар арасында килеп чыккан бәхәсләр;

әгәр дәүләтара килешүләрдә каралган булса, Татарстан Республикасының дәүләт органнары белән башка дәүләтләр арасындагы икътисади килешүләр аркасында килеп чыккан бәхәсләр;

законнарда Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды вәкаләтләренә кертелгән идарә өлкәсендәге башка бәхәсләр.

7 маддә. Арадашчы судына һәм арадашчыга мөрәҗәгать итү хокукы

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды эшне карауга кабул ителгәнче якларның килешүе аркасында килеп чыккан яисә килеп чыгарга мөмкинлеге булган Татарстан Республикасының Югары

арбитраж суды карамагындагы икътисади бәхәсләрне арадашчы судның хәл итүенә тапшырырга мөмкин.

Арадашчы судның карары билгеләнгән вакытта ирекле рәвештә башкарыла.

Карар билгеләнгән вакытка җаваплы як тарафыннан үтәлмәгән тәкъдирдә, Арбитраж гамәли мәҗмуга билгеләгән тәртиптә үтәлә.

Яклар бәхәсне хәл итү буенча гамәлләрне үзләре үк яисә уртак килешү нигезендә сайланган арадашчы аша кабул итәргә хаклы.

8 маддә. Бәхәсләрне хәл иткәндә Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды тарафыннан кулланыла торган законнар

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды бәхәсләрне Татарстан Республикасы Конституциясенә, әлеге Законга, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка закон актларына, дәүләтара һәм республикаара аңлашманамәләргә һәм килешүләргә таянып хәл итә.

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды бәхәсне хәл иткән дәвердә дәүләт органының һәм башка органның норматив актларының Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасының башка законнарына туры килмәвен ачыкласа, Татарстан Республикасының закон актлары нигезендә карар чыгара.

Бәхәсле мөнәсәбәтләрне хәл итәрлек законнар булмаган очракта, Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды шуңа охшашлы бәхәсләрне җайга сала торган законнар кабул итә, ә андый законнар булмаган очракта, законнарның гомуми башлангычыннан һәм асылыннан чыгып эш итә.

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды закон яисә аңлашманамә нигезендә чит илләрнең хокук нормаларын һәм халыкара хокук нормаларын куллана.

9 маддә. Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды карарларының мәҗбүрилеге

Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының Закон көченә кергән карарының, билгеләмәсенең Татарстан Республикасының бөтен территориясендәге барлык органнар, предприятиеләр, учреждениеләр, урындагы затлар, эшкуар гражданнар тарафыннан үтәлеше мәҗбүри.

10 маддә. Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының закон чыгару инициативасына хокукы

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Югары Советында закон чыгару инициативасы хокукына ия.

11 маддә. Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды составы

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды составына түбәндәгеләр керә: Рәис, беренче урынбасар, рәис урынбасарлары, коллегия рәисләре һәм судьялар - арбитраж суды әгъзалары.

Татарстан Республикасының Югары арбитраж судында түбәндәгеләр эшли:

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды пленумы;

икътисади бәхәсләр буенча эшләрне хәл итү буенча коллегия;

идарә өлкәсендә килеп чыгучы бәхәсләр хакындагы эшләрне хәл итү буенча коллегия;

закон көченә кермәгән карарларның законлылыгын һәм нигезлелеген кассация тәртибендә тикшерү буенча коллегия;

закон көченә кергән карарларның законлылыгын һәм нигезлелеген күзәтү тәртибендә тикшерү буенча коллегия.

12 маддә. Татарстан Республикасының Югары арбитраж судын сайлау

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды сайлану нигезендә төзелә.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының шәхси составы Татарстан Республикасының Югары Советы Рәисе тәкъдиме нигезендә Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан сайлана.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының Рәисе урынбасары, коллегия рәисләре, судьялары урынына кандидатуралар Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының белгечлек коллегиясе бәяләмәсе буенча Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Рәисе тарафыннан сайлап алына.

Судьялар урынына кандидатуралар , Татарстан Республикасының Югары Советы карамагына чыгарганчы, Татарстан Республикасы Югары Советының даими комиссияләре утырышларында тикшереләләр.

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды судьясы итеп 25 яшькә җиткән, 60 яшьтән /ир-атлар өчен/ һәм 55 яшьтән /хатын-кызлар өчен/ өлкән булмаган,югары юридик белеме һәм юридик белгечлек буенча ким дигәндә 3 ел эш стажы булган Татарстан Республикасы гражданы сайлана ала.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының вәкаләтләр чоры чикләнмәгән.

13 маддә. Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Рәисе

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Рәисе:

Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының һәм аның аппаратының эшчәнлеген оештыра;

урынбасарларының вазыйфаларын бүлә һәм үзенә закон тарафыннан бирелгән вәкаләтләр чикләрендә аларның вазыйфаларын билгели;

Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының структур бүлекчәләрен төзи;

суд хезмәткәрләрен /әлеге закон нигезендә сайланучыларыннан тыш/ урыннарына билгели һәм эшләреннән азат итә;

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды пленумын җыя һәм аның утырышларында рәислек итә;

үзенә закон нигезендә бирелгән башка вәкаләтләрне башкара.

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Рәисе Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды утырышларында, шулай ук Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды коллегияләренең утырышларында рәислек итәргә хаклы.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының Рәисе дәүләт органнарының һәм башка органнарның норматив актларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвен тикшерү турында һәм аларның Конституциягә туры килмәвен тану турында тәкъдимнәрен Татарстан Республикасының Конституция суды карамагына кертә.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының Рәисе Татарстан Республикасы Югары Советы, аның Закон чыгару җыены, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты утырышларында, шулай ук аларның президиумнары утырышларында катнаша ала.

14 маддә. Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Рәисенең урынбасарлары

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Рәисенең урынбасарлары суд утырышларында, шул исәптән аның коллегияләре утырышларында рәислек итә ала.

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Рәисенең урынбасарлары Татарстан Республикасы Югары Советы, аның Закон чыгару җыены, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты утырышларында, шулай ук аларның президиумнары утырышларында катнаша ала.

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Рәисе булмаган очракта аның вәкаләтләрен Рәиснең беренче урынбасары, ә беренче урынбасар да булмаган очракта Рәис урынбасарларының берәрсе башкара.

15 маддә. Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды коллегияләренең рәисләре

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды коллегияләренең рәисләре:

коллегия эшен оештыралар һәм суд составын төзиләр;

суд утырышларында, шулай ук суд коллегияләре утырышларында рәислек итәләр;

Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының пленумында коллегияләр эшчәнлеге хакында хисап тоталар.

16 маддә. Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды судьялары

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Рәисе, Рәис урынбасарлары, коллегияләр рәисләре һәм суд әгъзалары /судьялар/ Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының судьялары булалар.

Судья, эш буенча бәхәсләшүче якларны килештерергә тырышып, эшләрне хәл итүне оештыра; Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының карарлары буенча шикаятьләрне /килешмичә, каршы килүләрне/ карауда катнаша; Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының законнарны куллану тәҗрибәсен өйрәнә һәм гомумиләштерә, аны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли; законнарны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли; закон тарафыннан үзенә йөкләтелгән башка вазыйфалар башкара.

Судьялар арбитраж суд утырышларында теләсә кайсы мәсьәләне хәл иткәндә тигез хокуклардан һәм тигез мөмкинчелекләрдән файдаланалар.

Судьялар арасында эшләрне бүлү Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Регламенты билгеләгән, Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды пленумы раслаган нигезләр буенча башкарыла.

Судьяның вәкаләтләр чоры чикләнмәгән.

Судья алыштырылмый, аның кагылгысызлыгы закон тарафыннан гарантияләнә, һәм ул, үз ризалыгыннан гайре, башка эшкә күчереләалмый.

Судья каралучы эш турында фикерен, арбитраж суд утырышларыннан тыш, кайда да булса халык алдында әлеге эш буенча карар чыгарылганчы әйтергә тиеш түгел.

Судьялар Татарстан Республикасы Югары Советы билгеләгән тәртиптә аттестация узалар, шуның нәтиҗәсендә, белгечлеген һәм эш тәҗрибәсен исәпкә алып, белгечлек дәрәҗәсе /квалификация классы/ бирелә.

17 маддә. Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды судьяларының хокуклары

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды судьялары эшләрне хәл иткәндә түбәндәгеләргә хаклы:

дәүләт органнарыннан һәм башка органнардан, предприятиеләрдән, учреждениеләрдән, урындагы затлардан һәм эшкуар гражданнардан закон тарафыннан аларга йөкләтелгән вазыйфаларын башкаруга бәйле карарларының үтәлешен таләп итәргә;

дәүләт органнарыннан һәм башка органнардан, предприятиеләрдән, шул исәптән фәнни учреждениеләрдән һәм мәгълүмат үзәкләреннән, шулай ук урындагы затлардан кирәкле мәгълүмат һәм дәлилләр соратып алырга;

предприятиеләргә, учреждениеләргә, дәүләт органнарына һәм башка органнарга, урындагы затларга мәгълүм булган закон бозулар һәм аларны бетерү турында шәхси билгеләмәләр җибәрергә.

Судьяның дәүләт органнарына һәм башка органнарга, предприятиеләргә, урындагы затларга һәм эшкуар гражданнарга үз вәкаләтләре чикләрендә куела торган таләпләре мәҗбүри.

Судья шулай ук эшчәнлеген тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы закон актларында билгеләнүче башка вәкаләтләргә дә ия.

18 маддә. Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясының вазыйфалары

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясы үз эшчәнлеген башкарганда таләпләрен төгәл үтәргә һәм гадел булырга тиеш.

Судья башка дәүләт, хуҗалык органнарында һәм оешмаларында, иҗтимагый органнарда һәм оешмаларда түләүле вазыйфалар башкара алмый, эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә алмый.

Судьяга фәнни һәм укыту эшчәнлеге белән шөгыльләнергә рөхсәт ителә.

Судья хезмәт вазыйфаларын башкарганда, шулай ук хезмәттән тыш мөгамәләсендә гадел хөкем абруен, судья дәрәҗәсен төшерерлек яисә үзенең гаделлегенә һәм риясызлыгына шик тудырырлык гамәллердән сакланырга тиеш.

19 маддә. Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының һәм аның судьяларының бәйсезлеге

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды һәм аның

судьялары бәйсез һәм мөстәкыйль булалар, үз эшчәнлекләрен башкарганда бары тик законга гына буйсыналар. Төрле органнарның, предприятиеләрнең һәм урындагы затларның Югары арбитраж суды һәм судьялары эшчәнлегенә ничек тә булса тыкшынулары рөхсәт ителми, һәм бу закон нигезендә җаваплылыкка китерә.

Югары арбитраж суды судьясы сәяси фиркаләрдә, хәрәкәтләрдә тора һәм аларга матди ярдәм күрсәтә алмый, сәяси гамәлләрдә катнаша алмый, сәяси үгетләү һәм өндәүләр алып бара алмый. Ул шулай ук теге яисә бу оешмаларның һәм хәрәкәтләрнең, сәяси максатлар куймауларына да карамастан, җитәкләүче составларына керә алмый.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды карарлары судьяларның көнкүреш максатларыннан һәм сәяси омтылышларыннан азат булган хокукый карарларын чагылдыра.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьялары эшләрне үз ихтыярларын белдерү ирегенә читтән басым ясамый торган шартларда карыйлар. Алар нинди дә булса органнардан һәм урындагы затлардан күрсәтмәләр соратып алырга тиеш түгелләр.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьялары дисциплинар җаваплылыкка Татарстан Республикасы Югары Советы билгеләгән тәртиптә генә җәлеп ителә алалар.

Судья арбитраж суды утырышында белдергән фикере өчен, шулай ук суд тарафыннан карар кабул итү белән бәйле тавыш бирү нәтиҗәләре аркасында нинди дә булса җаваплылыкка тартыла алмый.

Судьяларның бәйсезлеге, аларның алыштыргысызлыгы, алар-

ны сайлау һәм азат итү тәртибе, эшләрне хәл итүнең юридик гамәлләре нигезендә, Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының эшчәнлеге өчен тиешле шартлар булдыру, шулай ук судьяларны матди һәм җәмгыяви тәэмин итү белән билгеләнә.

Массакүләм мәгълүмат чараларының үз хәбәрләрендә Татарстан Республикасы Югары арбитраж судында карала торган аерым эш буенча, суд тарафыннан карар кабул ителгәнчегә кадәр, тикшерү нәтиҗәләре хакында фараз кылырга хаклары юк.

20 маддә. Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларының кагылгысызлыгы

Югары арбитраж суды судьясы, Татарстан Республикасы Югары Советы, ә сессияләр арасында - Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы рөхсәтеннән башка, җинаять җаваплылыгына җәлеп ителә, кулга алына, мәҗбүри рәвештә тотып алып китерелә яки хөкем тәртибендә салына торган административ җәзага тартыла алмый.

Җинаять кылуда гаепләнеп кулга алынган яисә административ хокук бозулар турында эшләрне карау тәртибендә эчке эшләр органына тотып китерелгән Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясы, шәхесе ачыклануга, кичекмәстән азат ителергә тиеш.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясының торагына яисә эш бүлмәсенә, шәхси яки ул файдалана торган башка транспортка үтеп керү, анда тикшерену, тентү уздыру яисә әйберләрен алып чыгу, арбитраж суды судьясын шәхси тикшерү һәм аңа шәхси тентү уздыру, шулай ук аның әйберләрен һәм документларын тикшерү яисә алу бары тик Татарстан Республикасы Прокуроры санкциясе нигезендә һәм әлеге судьяга карата эш кузгатылган очракта гына башкарыла ала.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясына карата җинаять эше, шулай ук административ хокук бозу турында эш бары тик Татарстан Республикасы Прокуроры тарафыннан гына кузгатыла ала.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларына карата җинаять эшләре бары тик Татарстан Республикасы Югары суды тарафыннан гына каралырга тиеш.

21 маддә. Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясының вәкаләтләрен туктатып тору

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясының вәкаләтләре Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы карары нигезендә туктатылып торырга мөмкин, әгәр:

законда билгеләнгән тәртиптә судьяны җинаять җаваплылыгына җәлеп итүгә яисә аны кулга алуга ризалык бирелгән булса;

закон судьяны хезмәт вазыйфаларына туры килми торган эшләр белән шөгыльләнә дип тапса;

судья, сәламәтлегенә бәйле рәвештә, озак вакыт үзенең вазыйфаларын үти алмаса;

карала торган эш буенча суд карар кабул иткәнчегә кадәр судья массакүләм мәгълүмат чараларында әлеге эш хакында үз фикерен белдерсә.

Судьяның вәкаләтләре сәбәпләр ачыклангancы туктатып торыла.

Судьяның вәкаләтләрен туктатып тору судьяга хезмәт хакы түләүне туктатып торуга яисә аның күләмен киметүгә китерми һәм аны әлеге Законда билгеләнгән кагылгысызлык гарантияләреннән мәхрүм итми.

22 маддә. Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясының вәкаләтләрен туктатуның сәбәпләре

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясының вәкаләтләре түбәндәге сәбәпләр аркасында гына туктатылырга мөмкин:

судның закон көченә кергән гаепләү карары булганда;

хезмәткә сәләтсезлек турында судның закон көченә кергән карары булганда;

үлү турында таныклык яисә үлемен игълан итү /хәбәрсез югалганын тану/ турында судның закон көченә кергән карары булганда;

эшен дәвам итә алмаслык каты авыруы яисә гарипләнүе турында табип бәяләмәсе булганда;

сайланып куела торган башка урынга сайлану турында документы булганда;

вәкаләтләреннән баш тарту турында шәхси гаризасы булганда.

Башка барлык очракларда судьяларның вәкаләтләрен туктату дөрес түгел.

Судьяларның вәкаләтләрен туктату Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан раслана.

23 маддә. Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды судьясына ихтирамсызлык күрсәткән өчен җаваплылык

Хөкем гамәлләрендә катнашучылар яисә суд утырышында катнашучы затлар тарафыннан Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясына ихтирамсызлык күрсәтү, шулай ук кем дә булса берәү тарафыннан ачыктан-ачык судьяны кимсетә торган гамәлләр кылу Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплылыкка җәлеп итүгә китерә.

24 маддә. Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды пленумы

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды эшчәнлегенең мөһим мәсьәләләрен карау өчен Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының пленумы оештырыла.

Пленум кимендә кварталга бер мәртәбә чакырыла.

Пленум составына Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының Рәисе, аның урынбасарлары, пленум сәркатибе, коллегияләр рәисләре һәм Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды судьялары керә.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды пленумының утырышларында Татарстан Республикасының Конституция суды Рәисе, Татарстан Республикасы Прокуроры, Татарстан Республикасының юстиция министры, шулай ук Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Рәисе чакыруы буенча килгән башка затлар катнаша ала.

Пленум утырышында исемле составның кимендә өчтән икесе катнашса, ул вәкаләтле санала.

Мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре хакындагы пленум карары ачык тавыш белән кабул ителә. Утырышта катнашучы пленум әгъзаларының күпчелеге хуплап тавыш бирсә, карар кабул ителгән дип санала. Карар белән килешмәгән пленум әгъзасы үз фикерен белдерергә хаклы, ул карарга беркетеп куела.

Пленум карарына Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Рәисе һәм пленум сәркатибе тарафыннан имза салына.

25 маддә. Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды пленумының сәркатибе

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды пленумы сәр-

катибе пленум тарафыннан Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьялары арасыннан биш елга сайлана.

Пленум сәркатибе судьялык вазыйфаларын башкару белән бергә:

пленум утырышларын әзерләү белән шөгыльләнә;

пленум утырышлары беркетмәләрен алып баруны, шулай ук пленум әгъзаларын мәгълүмат белән тәэмин итүне оештыра;

пленум карарларының үтәлешен тикшерә;

пленум карарларын тиешле органнарга, предприятиеләргә һәм гражданнарга җибәрүне оештыра.

26 маддә. Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды пленумының вәкаләтләре

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды пленумы:

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды тарафыннан законнарны куллану тәҗрибәсенең гомумиләштерелгән материалларын карый;

хөкем карарын аңлату тәртибендә Татарстан Республикасы законнарын куллану мәсьәләләре буенча күнелеш бирерлек аңлатмалар тәкъдим итә;

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Рәисенең, Татарстан Республикасы Прокурорының Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының закон көченә кергән карарларына һәм теркемнәрнең закон көченә кергән карарларының законлылыгын һәм нигезлелеген тикшерү буенча карарларына каршылык белдерү эшләрен күзәтү тәртибендә карый. Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды пленумы тарафыннан күзәтү тәртибендә кабул ителгән карарларның барлык органнар, предприятиеләр, учреждениеләр, урындагы затлар һәм эшкуар гражданнар тара-

27 статья. Законнарны куллану тәҗрибәсен гомумиләштерү

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды законнарны куллану тәҗрибәсен өйрәнә һәм гомумиләштерә, тәҗрибәне камилләштерү һәм бердәйләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли һәм гамәлгә ашыра, тәҗрибә уртаклашу максатында, законнарны куллану тәҗрибәсен анализлый.

28 статья. Законнарны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды законнарны куллану тәҗрибәсен өйрәнү һәм гомумиләштерү нигезендә законнарны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли һәм аларны билгеләнгән тәртиптә кертә.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды, предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең җитәкчеләре белән килешеп, әлеге эшкә аларның белгечләрен һәм галимнәрен җәлеп итәргә хаклы.

фыннан үтәлеше мәжбүри;

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Рәисе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды коллегияләренең составын, шулай ук пленум сәркатибен раслый;

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды коллегияләре рәисләренең тиешле судьялар һәм коллегияләр эшчәнлеге турындагы нотыкларын тыңлый;

закон чыгару инициативасы тәртибендә Татарстан Республикасы Югары Советына тәкъдимнәр, шулай ук закон чыгаруны камилләштерү буенча башка органнарга тәкъдимнәр кертү турындагы мәсьәләләрне карый;

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды пленумы аңлатмаларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы Татарстан Республикасы Конституция суды тәкъдимнәрен карый һәм тиешле карарлар кабул итә;

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларының белгечлек коллегиясен сайлый һәм аның эшчәнлеге турында хисапларын тыңлый.

29 маддә. Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды каршындагы фәнни-консультатив совет

Законнарны куллану тәҗрибәсен оештыру һәм аны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү белән бәйле мәсьәләләр буенча фәнни нигезләнгән тәкъдимнәр әзерләү өчен Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды каршында фәнни-консультатив совет төзелә.

Фәнни-консультатив советның составы һәм аның турында положение Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Рәисе тарафыннан раслана.

Фәнни-консультатив совет киңәшләшү органы булып тора, һәм ул җәмәгатьчелек тәртибендә эшли.

30 маддә. Хужалык итү законнарын бозуларны кисәтү

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды хужалык итү законнарын бозуларны кисәтү йөзеннән түбәндәге эшләрне башкара:

икътисади мөнәсәбәтләрдә закон бозуларның сәбәпләрен билгели торган мәгълүматларга һәм материалларга анализ ясый, үз вәкаләтләре чикләрендә әлеге сәбәпләрне бетерү буенча чаралар әзерли һәм куллана;

эшләрне турыдан-туры предприятиеләрдә хәл итә;

үз инициативасы белән арбитраж эшләр кузгата;

предприятие җитәкчеләренә, дәүләт органнарына һәм башка органнарга законнарны бозулары хакында, мондый хокук бозуларга китерүче сәбәпләр һәм тиешле гамәлләр кылуны таләп итүче шартлар турында шәхси билгеләмәләр җибәрә;

мәгълүм булган закон бозулар хакында прокуратура органнарына хәбәр итә;

икътисади мөнәсәбәтләрдә хужалык итү законнарын аеруча җитди бозулар турында Татарстан Республикасы Югары Советына хәбәр итә һәм алар хакында Татарстан Республикасының Министрлар кабинетына белдерә.

31 маддә. Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының төзелеше, саны һәм аны акча белән тәэмин итү

Хөкем эшләре материалларын әзерләү һәм уздыру, законнарны куллану тәҗрибәсен өйрәнү һәм гомумиләштерү, законнарны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү, Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының башка вазыйфаларын үтәү өчен бүлекләрдән һәм структур бүлекчәләрдән торган арбитраж суд аппараты төзелә.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж судын тоту өчен чыгымнарның күләме һәм хезмәткәрләренең штат берәмлекләре Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Рәисе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасының республика бюджеты исәбеннән Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан раслана.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды аппаратының төзелеше һәм штатлары Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Рәисе тарафыннан раслана.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж судын матди-техник яктан һәм эш бинналары белән , шул исәптән һәр судьяны киңәшләшү бүлмәләре һәм хөкем утырышлары заллары белән тәэмин итү, шулай ук аның хезмәткәрләренә шифаханәдә-курортта дәвалану, аларга табип, торак һәм җәмгыяви-көнкүреш хезмәте күрсәтү Татарстан Республикасының республика бюджеты исәбеннән Татарстан Республикасының Министрлар кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасының Югары арбитраж судын финанслау Татарстан Республикасының республика бюджетында аерым юл итеп күрсәтелә.

32 маддә. Статистик хисап

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды билгеләнгән тәртиптә статистик хисап алып бара һәм үз эшчәнлеге турында статистик мәгълүматларга анализ ясый.

33 маддә. Хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек
һәм халыкара элемтәләр

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек итә.

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды билгеләнгән

тәртиптә халыкара элемтәләр урнаштыра.

34 маддә. Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларының белгечлек коллегиясе

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларының белгечлек коллегиясе Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьялары арасыннан рәис, аның урынбасары һәм өч әгъзасы составында Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды пленумы тарафыннан яшерен тавыш бирү юлы белән биш елга сайлана.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Рәисе һәм аның урынбасарлары белгечлек коллегиясе составына кермиләр.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларының белгечлек коллегиясе үзенең эшчәнлеге хакында Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды пленумы каршында хисап тота.

35 маддә. Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларының белгечлек коллегиясе вәкаләтләре

Белгечлек коллегиясе:

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьялары урынына кандидатлар күрсәтү мөмкинлеге турында бәяләмә бирә;

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларына белгечлек аттестациясе уздыра;

әлеге Законның 20 һәм 21 маддәләрендә каралган нигезләрдә Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларының вәкаләтләрен туктатып тору һәм туктату турында бәяләмә бирә;

судьяларның дисциплинар җаваплылыгы турындагы мәсьәләләрне карый;

судьяның вазыйфасын күтәрү мөмкинлеге турында бәяләмә бирә;

судьяга чираттагы белгечлек сыйныфы бирү яисә судьяны элек бирелгән белгечлек сыйныфында калдыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирә.

36 маддә. Аттестация

Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының, техник хезмәткәрләреннән гайре, барлык хезмәткәрләре дә закон нигезендә аттестация узарга тиеш.

Аттестацияләү тәртибе турындагы положение Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Рәисе тарафыннан раслана.

37 маддә. Хөкем хакимияте символлары һәм Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының хокукый халәте

Югары арбитраж суды бинасына Татарстан Республикасының Дәүләт флагы куела, ә хөкем залларында шулай ук Татарстан Республикасының Дәүләт флагы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте урнаштырыла.

Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды әлеге Закон нигезендә юридик зат булып санала.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте төшерелгән, татар һәм урыс телләрендә үз исеме язылган мөһергә ия.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларына Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы тарафыннан таныклыклар бирелә.

38 маддә. Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының эшләү урыны

Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының даими эшләү урыны булып Татарстан Республикасының башкаласы - Казан шәһәре санала.

Татарстан Республикасының башка торак пунктларында Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды составында беренчел баскычтагы төбәк судлары оештырылырга мөмкин.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
1992 елның 22 декабре
№ I680-XП